КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 декабрь г.Казань № 1757

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында

Россия Федерациясе гражданнарының түләүсез медицина ярдәме күрсәтүгә конституциячел хокукларын тәэмин итү максатларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре программасы турында» 2023 елның 28 декабрендәге 2353 номерлы карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2024 елда Программа кысаларында күрсәтелгән медицина хезмәтләре өчен исәп-хисапларны тәмамлау 2025 елның 15 февраленә кадәр гамәлгә ашырыла;

Программаны тормышка ашыруда катнашучы медицина оешмалары тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар нигезендә мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендәге эшчәнлек турында хисаплылык һәм Программаны раслаган көннән 14 көн эчендә – тиешле финанс елына финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары кертелә;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасы буенча медицина ярдәменә түләү турында тариф килешүе төзү буенча;

медицина оешмалары тарафыннан нигездә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күрсәтелә торган медицина ярдәме күрсәтү тарифларын һәм алар өчен түләү тәртибен эшләү һәм аларны мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру кысаларында медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләү тарифлары комиссиясенә раслауга кертү буенча;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, рәсми сайтта Программаны һәм медицина ярдәменә түләү өчен билгеләнгән тарифларны урнаштыру буенча;

2024 елның 15 февраленә кадәр медицина оешмаларының килештерелгән финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә кертүне тәэмин итү буенча;

квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазын сатып алу һәм ремонтлау чаралары планын билгеләнгән тәртиптә раслау буенча;

квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазын сатып алу һәм ремонтлау чаралары планына кертү өчен чараларны сайлап алу критерийларын раслау буенча.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 116-ТРЗ номерлы һәм «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 117-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарында әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Программаны гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

4. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин